**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ**
**КАРАРЫ**

**№ 1** **22.11.2019ел**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы
Урсай авыл җирлеге составына керүче
Мөслим авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2019 елның 22 ноябрендә түбәндәге сорау буенча узган, гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде:

« Сез 2020 елда Урсай авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, 1 Төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, 350 сум күләмендә, 2 төркем инвалидлардан түләүне киметеп, аны 175 сум (50%) күләмендә билгеләп, үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- юлларга щебенка җәю (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү) Такташ ур.,Мөслим авылы;
- Мөслим авылында урамнарны яктырту, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, энергияне саклый торган лампаларны урнаштыру, килешү буенча эш өчен түләү;
- Мөслим авылында территориядә җыештыру, көнкүреш калдыкларын һәм чүп-чарларны вакытлыча җыю, чистарту;
- Мөслим авылында юлларны кардан чистарту;
- Мөслим авылында җәй көне территорияне чабу;
- Мөслим авыллында су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау (материал, җиһазлар сатып алу, өзеклекләрне бетерү, торбаларны алыштыру, килешү буенча эш өчен түләү);
- Мөслим авыллында артезиан скважиналарына насослар сатып алу.
- Мөслим авылында урам күрсәткечләрен ике телдә ясау һәм урнаштыру.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда, сайлау хокукына ия булучы катнашучылар исемлегендә 143 кеше теркәлгән, җыенда тавыш бирүдә катнашучылар саны - 106 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

халык җыенында катнашучы 106 кеше «Әйе» позициясе өчен тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар чыгарды:

1. Азнакай муниципаль районы Үрсай авыл җирлеге составына керүче Мөслим авылыдна узган халык җыенын узган, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Түбәндәге сорау буенча карарны кабул итәргә: « Сез 2020 елда Урсай авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, 1 Төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, 350 сум күләмендә, 2 төркем инвалидлардан түләүне киметеп, аны 175 сум (50%) күләмендә билгеләп, үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- юлларга щебенка җәю (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү) Такташ ур.,Мөслим авылы;

- Мөслим авылында урамнарны яктырту, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, энергияне саклый торган лампаларны урнаштыру, килешү буенча эш өчен түләү;

- Мөслим авылында территориядә җыештыру, көнкүреш калдыкларын һәм чүп-чарларны вакытлыча җыю, чистарту;

- Мөслим авылында юлларны кардан чистарту;

- Мөслим авылында җәй көне территорияне чабу;

- Мөслим авыллында су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау (материал, җиһазлар сатып алу, өзеклекләрне бетерү, торбаларны алыштыру, килешү буенча эш өчен түләү);

- Мөслим авыллында артезиан скважиналарына насослар сатып алу.

- Мөслим авылында урам күрсәткечләрен ике телдә ясау һәм урнаштыру.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштырырга:

-Россия, Татарстан Республикасы, Азнакай районы, Урсай авылы, Үзәк урамы, 65 йорт.

-Россия, Татарстан Республикасы, Азнакай районы, Мөслим авылы, Гафури урамы, 31 йорт;

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Үрсай авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Урсай авыл җирлеге Башлыгы И.А.Абдуллин